## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 16 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән  500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Чураш авылы зиратына баручы юлны хэм Комсомол урамы юлын ремонтлау   вак таш жэю ( вак таш таш ташу);
- Чураш авылы зиратына триммер алу;
- Чураш авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;
-Чураш авылында урнашкан памятникны ремонтлау(брусчатка жэю );
-сабантуй уткэрэ торган урынга  урам туалеты алу;
-кыш көне Чураш авылларындагы юлларны кардан чистарту;
- район газетасында некрологларны бастырып чыгару;

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау  авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау  авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева